**Шәтке урта гомум белем бирү мәктәбе.**

# Укытучылар көненә багышланган бәйрәм программасы.

Педагог-оештыручы:Музафарова С.Ю.

2015-2016 нчы уку елы

Укытучылар көненә багышланган бәйрәм программасы.

СЕЗНЕҢ ХЕЗМӘТЛӘРГӘ ҺӘЙКӘЛ КУЕП,
СЕЗНЕҢ АЛДА БАШНЫ ИЯБЕЗ...

1. - Исәнмесез! - диеп башлыйм әле,
Исәнләшкәч, күтәрелә күңел.
Авырлыклар эреп юкка чыксын,
Кайгы-сагыш безгә кирәк түгел.

2. -Хәерле көн!- диеп бер елмайсаң,
Бар дөньяны нурга күмәсең.
Иртәдән үк шат кәефле булсаң,
Бәхет диңгезендә йөзәсең.

**2 а.б.** Әйе,__________, Шушы зур, якты һәм матур мәктәбебездә белем алабыз. Көн дә сөенеп мәктәбебезгә укырга киләбез. Безне һәр иртән елмаеп яраткан укытучыларыбыз каршы ала.

**1 а.б.** Укытучым... Бүген галим дә, ташчы да, иген игүче дә олы исемең алдында баш ия., теләсә кайсы һөнәргә юл башы синең фидакарь хезмәтең нәтиҗәсендә салына. Син дөньядагы барлык уңай сыйфатларны үзеңә туплагансың. Синдәге сабырлык аналар сабырлыгына тиң. Шушы катлаулы чорда да көндәлек мәшәкатьләрне читкә куеп, башкалар өчен яшисең. Авыр, ләкин дөньядагы иң кирәкле хезмәтне бар көчеңне куеп башкарасың. Нарасый күңеленә син чәчкән игелек орлыклары шытымнар бирсен, үссен, корымасын иде.

**2 а.б..** Укытучы! Бәйрәмең белән сине! Уңышларыңа сөенеп, бәхет хисе кичереп яшә! Һәр таңны сау-сәламәт каршыла. Замана авырлыклары, күңел төшенкелеге киләчәктә сине читләтебрәк үтәргә тырышсын.

**1 а.б**.. Безнең өчен иң талантлы, акыллы, матур кешеләр – яраткан укытучыларыбыз. Барлык укучылар исеменнән сезгә олы хөрмәтебезне һәм чиксез рәхмәтебезне белдерәбез.

***Җыр:* __________________________________**

**2 а.б..** Укытучы хезмәтенең авырлыгын шул һөнәр иясе үзе генә тулысынча тоя, аңлый һәм кичерәдер, минемчә. Күпме сабырлык, түземлек, йокысыз төннәр, шатлыклы да, кайвакытта борчулы да көннәр кичергәнен бу олуг зат үзе генә беләдер. Шуңа күрә ул һәркем тарафыннан яратылучы, хөрмәт ителүче - УКЫТУЧЫ!

**1 а.б..** Безнең укытучылар коллективы үзенең ныклы белемле, фантазиягә бай, иҗади, сәләтле, намус белән хезмәт итүче, балаларны чын күңелдән яратучы укытучылары белән данлыклы. Коллективта бүгенге көндә 20 укытучы һәм тәрбияче балаларга белем һәм тәрбия бирә. Бүген аларның һөнәри бәйрәмнәре.

Бәйрәмнәрдә - бәхет тантанасы,
Җан сафлыгы, күңел яктысы.
Гомер буе озатып бара безне
Бәйрәмнәрнең керсез ак төсе.

**2 а.б..__________**, әйдә,  бу  бәйрәм көнендә, мәктәбебездәге һәр укытучыга узебезнең уй-теләкләребезне,фикерләребезне әйтеп карыйк әле.

**1 а.б.** Әйдә __________, Әйтеп карыйк соң.

**2 а.б.. ДИРЕКТОР** – Мәктәпнең тоткасы. Ул безнең барлык проблемаларыбыз чишелешен тәэмин итүче - **Ибушев Алексанр Алексеевич** эшли бу җаваплы  постта. Укытучылар көнен, директор буларак, __31_ нче елын каршылый.  Шук, шаян, җор телле, шат күңелле, юморга бай директорыбызның мәңге яшь, нык егәрле булып калуын, киртәләрне егып, дулкыннарны кичеп, артыннан безне дә ияртеп алга һәм бары тик алга гына хәрәкәт итүен телибез. Сез безнең хәтердә яхшы дус, киңәшче буларак сакланып калырсыз. Бәйрәм белән Сезне.

**1 а.б.. Мәктәпнең укыту-тәрбия эшләре буенча директор урынбасары, информатика, тормышта имин яшәү серләрен һәм хәрби хезмәткә өйрәтүче укытучыбыз Музафаров Илнар Гыйлфан улы.** Сезгә эшегездә зур уңышлар, сәламәтлек һәм сабырлык телибез. Бәйрәмегез котлы булсын.

**2.аб.**      Мәктәпнең тәрбия буенча директор урынбасары **Шәйхиева Илсөяр** Миннахматовна.  Сезгә шушы авыр, әмма мактаулы эшегездә сәламәтлек, тынычлык, сабырлык, гаилә бәхете телибез. Һәрвакыт шулай олы йөрәкле, кешелекле булып калыгыз. Бәйрәмегез белән котлыйбыз.

---

**1 а.б..** Мин – татар , -дим, шуңа шатланам,
Сөйләр өчен татар телем бар.
Күп милләтне үзенә сыйдырган
“Татарстан” дигән илем бар.

Туган телебезнең серләренә төшенергә, аны яратырга, туган җирдә яшәүнең тәмен белергә өйрәтүче, укучыларның иҗади сәләтләрен үстерүдә зур роль уйнаучы **татар теле һәм әдәбияты укытучылары Габделхаева Рәзифә Хакимзяновна һәм Заляева Гөлфия Мөхәммәтвасиловна** да бәйрәм котлауларына бик тә лаек. Шул ук вакытты музыка фәненнән һәм физкультура фәннәреннән белем бирәләр. Яраткан укытучыларыбызга теләкләрнең һәммәсен – саулык, озын гомер, бәхет, шатлыклар, гаилә иминлеге телибез.

**2 а.б..** ХӨРМӘТЛЕ УКЫТУЧЫЛАРЫБЫЗ!  Фәнис Яруллинның **“Сез кирәк” шигырен** сезнең хөрмәткә укып китәсе килә.

Без юлларга чыктык кына,
Күңелдә якты теләк.
Иң дөрес, иң туры юлны
Сайлашырга сез кирәк.

Алда көрәшләр дә булыр,
Югалып калсак кинәт –
Егылганда тотынырга,
Көч бирергә сез кирәк.

Сүнгән чакта өметебез,
Калмаган чакта терәк.
Күз яшьләрен сөртә-сөртә,
Юатырга сез кирәк.

Боекмас өчен күңелләр,
Кимсенмәс өчен йөрәк –
Сез кирәк, укытучылар,
Безгә һәрчак сез кирәк! (Ф. Яруллин)

**1 а.б..** Туган телебез – татар теле белән бер рәттән өйрәтелүче рус телен, рус язучыларының матурлыкка, гүзәллеккә, гаделлеккә чакыручы гүзәл сәнгать әсәрләрен биргән **рус теле һәм әдәбияты укытучылары Кадыйрова Сәвия Вакифовна һәм Закирова Фәния Мөнировна** бәйрәм котлауларын кабул итеп алсыннар!

**2 а.б.** Сезнең белән бүген горурланам,
Хөрмәтем зур сезгә йөрәктә,
Һәрбер сүзегез, һәрбер киңәшләрегез
Безне ялгышмаска өйрәтә.

Ходай сезгә сәламәтлек бирсен.
Бәхет, шатлык озата барсыннар.
Язмышлар да сезгә гел яхшылык
Гел уңышар гына язсыннар.

**1 а.б.. Инглиз телендә** сөйләшергә өйрәтүче укытучыбыз **Гафурова Гөлүсә Ибрагимовна**! Уңышлар юлдаш булсын сезгә, кайгы җиле беркайчан да капкагызны какмасын! Бәйрәм белән сезне!

Ихлас күңелдән юллыйбыз
Сезгә иң-иң изге теләкләр:
Озын булсын гомерегез
Тыныч булсын күңелегез.

**2 а.б..** - Мәсьәләмне чишә-чишә,
Катып бетте башларым.
Тагын бер чишеп карыйм да,
Чишелмәсә, ташлармын, - дип әйткән ди бер малай, математикадан өй эше итеп бирелгән мәсьәләне чишә алмагач. Аллага шөкер, мәсьәләләр, мисаллар тиз чишелә, чөнки чишәргә өйрәтүчеләребез әйбәт. **Математика укытучыларыбыз Идрисова Миләүшә Суфияновна һәм Хафизова Фәридә Алмасовна**!. Бәйрәмегез белән котлыйбыз сезне!

1. **А.б. Химия, биология укытучыбыз Габдуллина Резидә Габдулловна**!. Сабыр, түзем, нык ихтыяр көченә ия, игътибарлы, шәфкатьле апабызга да бәйрәм көнендә иң матур теләкләребезне генә юллыйбыз. Хәзер сезгә тәкъдим итәсе күңелле мизгелләребез, сезнең бәйрәмегезне тагын да күңеллеләндерер дип уйлыйбыз.

**2 а.б.** Безне күп серләргә өйрәтүче, кызыклы, мавыктыргыч, тормышта үзебез өчен кирәкле ачылар күрсәтүче **физика фәненнән белем бирүче, Валияхметова Зөхрә Мияссаровна!**

Бәйрәм белән Сезне, укытучым!

Йөрәгемнең якын кешесе.

Сезгә телим саулык, озын гомер,

Шәхси бәхет, дөнья рәхәтен.

Шәкертләрнең тырыш, инсафлысын.

Яхшы гамәл, Ходай рәхмәтен!

***<u>Мәзәкләр</u>***

1. **А.б.** Сайларга юллар күп булса да,
Максатка бер генә юл илтә.
Ялгышмый үз юлың сайласаң,
Бәхетле булырга шул җитә.
Күңелдә якты эз калдырып,
Ашкынып, көн арты көн үтә;
Һәр көнең сөенеч китерсә,
Бәхетле булырга шул җитә. (Ф. Яруллин)

2 **А.б.-** Әйе, бәхетле булыр өчен күп кирәкми. Тик саулыгың, сәламәтлегең булмаса, бәхетле булып яшәп булмыйдыр ул. Укучыларны **тормышта хезмәткә мәхәббәт тәрбияләүче укытучыбыз Закиров Наил Сабирович!.** Ул тормышта җәмгыятьтә үз урыныңны табарга һәм кешелеклелек сыйфатларына ия булу серләренә төшендерә. Укытучыбыз, сезгә бары тик зур уңышлар, гаилә тынычлыгы телибез.

<u>1 а.б.</u> **Тарих фәненнән белем бирүче Ибраева Зәлидә Солтановна! кызы** үзенең тирән эчтәлекле сөйләме белән генә дә һәр укучыны үзенә карата, яраттыра белә. Игътибарлы, ихтирамлы, үз эшенә ихлас бирелгән укытучы. Бәйрәм белән сезне!

**2 а.б..** Балалар коллективын **оештыручы Музафарова Сөмбел Юлдаш кызы** исә һәр тәрбияви чараны оештыруда тырышлыгын кызганмый, сәнгатькә гашыйк кеше. Сезгә иҗади уңышлар, гаилә тынычлыгы, сәламәтлек телибез.

Бәйрәмегез мөбәрәк булсын, хөрмәтле укытучылар!

***ҖЫР:***______________________________________________________

**1 а.б..** Күңелемнең аяз күгендә
Мәңге сүнмәс якты йолдыз сез..
Юл ачтыгыз белем серләренә,
Шуңа күрә безгә якын сез.

Тәүге дәрес әле һаман истә,
Онытыласы да юк аның.
Чишмә башы сез ул Әлифбаның –
Һәркем өчен изге доганың.

**2 а.б.** Әйе, **беренче укытучысын һәркем зурлап искә ала.** Безнең башлангыч сыйныф укытучылары **Давлетшина Рәзинә акимзяновна, Хусайнова Мөнирә Рауфовна, Шайхутдинова Роза Валериевна, Гимадиева Равия Сахабетдиновна** да күпме бала рәхмәтле бүген. Чөнки алар нәкъ менә шушы олы җанлы затлар тырышлыгы белән белем сукмагыннан беренче адымнарын атладылар һәм тайпылмый атлап баралар. Бәйрәмегез белән сезне!

1. **А.б.** Үзләренең бөтен гомерләрен балаларга белем һәм тәрбия бирүгә багышлаган, хәзерге көндә лаеклы ялда булган **ветеран укытучыларыбызга** да бәйрәм көннәрендә иң изге теләкләребез барып ирешсен иде. Менә алар: **Заляева Фирдәвес Нуриевна, Залялова Гөлсинә Тимировна, Венедиктова Вера Леонтьевна, Ибушева Әлфия Габделнуровна.**

**2 а.б.** Яшегез олы булса да, күңелегез яшь булсын.
Картаймагыз мәңге, мәңге, көчегез ташып торсын!
Рәхмәт сезгә!

**1 а.б.** Әйе, Безнең илдә кеше бәяләп бетерә алмаслык кыйммәтле хәзинә. Кешеләр илнең хуҗасы һәм тоткасы. Ә илебез киләчәгенең тоткасы сезнең кулларда, хөрмәтле укытучыларыбыз! Сез кешеләргә белем ачкычы бирәсез, кешеләрне кеше итәсез,олы юлга илтәсез. Сезгә барысы өчен олы рәхмәтебезне белдерәбез.

**2 а.б.**
Алтын яфрак ява урамнарга,
Сукмакларга ява, юлларга…
Урам буйлап атлый укытучы
Чумган килеш тирән уйларга…

Уйларыгыз изге…Сабыйларның
Күңеленә барып ялгана
Күпме хисләр кирәк алар өчен
Ял-йокыңны онытып янарга.

**1 а.б.**

Һәм сакларга кирәк сүндермичә
Аларга дип яккан учакны
Үз балаңа күпме җылы кирәк
Аларга да кирәк шул чаклы.

Йөрәгеңне бүлеп бирү кирәк
Җил-давыллар җирдә азмы соң?
Чандыр иңегезгә күтәргәнсез
Күпме балаларның язмышын!

**2 а.б.**

Без беләбез сезгә җиңел түгел
Күпме язмыш сезнең кулларда
Ләкин ышан һәрчак без булырбыз
Сез күрсәткән тугры юлларда!

**Җыр: «Сез иң гүзәл кеше икәнсез.»**

1. Хөрмәтле укытучыларыбыз! Тагын бер кат бәйрәмегез белән сезне!
2. Чын күңелдән рәхмәт,Сезгә!